КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 16 сентябрь г.Казань № 791

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының һәм «Этилен-600» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 17 октябрь, 1104 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының һәм «Этилен-600» индустриаль паркының идарәче компаниясенә – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыятенә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2022 ел, 17 октябрь, 1104 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 30 декабрь, 1475 нче; 2023 ел, 18 апрель, 487 нче; 2023 ел, 19 декабрь, 1638 нче; 2024 ел, 16 апрель, 257 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә

алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә татар текстында «субсидияләр бирү» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләрен өстәргә;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасы территориясендә индустриаль (сәнәгать) паркларны булдыру һәм үстерү» төбәк проекты чараларын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктта татар текстында «субсидияләр бирү» сүзләре алдына «Татарстан Республикасы бюджетыннан» сүзләрен өстәргә;

әлеге карар белән расланган Россия кредит оешмаларында һәм (яки) «ВЭБ.РФ» дәүләт үсеш корпорациясендә алынган кредитлар буенча төп бурычны һәм процентларны түләү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» индустриаль паркының һәм «Этилен-600» индустриаль паркының идарәче компаниясе – «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зонасы» акционерлык җәмгыяте чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин